КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 ноябрь г.Казань № 1437

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында

Кабинет Министров Республики Татарстан ПОСТАНОВЛЯЕТ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды акчасы исәбеннән төзелгән торак йортларда өстәмә салып төзелгән, шул исәптән төзелеше тәмамланмаган урыннарны сату турында» 2004 ел, 17 май, 241 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт җир резервларына кертү һәм алардан алга таба файдалану мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт җир резервлары фонды һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибен раслау турында» 2005 ел,

21 гыйнвар, 15 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 17 гыйнвар, 9 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт җир резервларына кертү һәм алардан алга таба файдалану мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт җир резервлары фонды һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибен раслау турында»;

преамбулада «һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервын оештыру тәртибе турында» 2004 ел, 21 декабрь, 255 нче боерыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт җир резервларына кертү һәм алардан алга таба файдалану мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт җир резервлары фонды һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибен расларга.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.»

әлеге карар белән расланган Җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт җир резервларына кертү һәм алардан алга таба файдалану мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт җир резервлары фонды һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт җир резервларына кертү һәм алардан алга таба файдалану мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт җир резервлары фонды һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибе»;

преамбулада «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды » сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт җир резервлары фонды» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт җир резервлары фонды» сүзләренә алмаштырырга,

2 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» акционерлык җәмгыяте;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча).»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

беренче абзацта «Попечительләр советы» сүзләрен «Совет» сүзенә алмаштырырга;

икенче абзацта «Күчемсез мөлкәт объектлары кадастры федераль агентлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе» сүзләрен «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

7.2 пунктның алтынчы абзацында «кадастр паспортлары күчермәләрен» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәне» сүзләренә алмаштырырга;

8 пункта «кадастр паспортлары» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә» сүзләренә алмаштырырга, «карары» сүзен «боерыгы» сүзенә алмаштырырга;

9 пунктта «карарын» сүзен «боерыгын» сүзенә алмаштырырга;

11 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «карары» сүзе үзгәрешсез кала;

икенче абзацта татар текстында «карары» сүзе үзгәрешсез кала;

13 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кирәкле документлар теркәлгән гаризаны Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрә;»;

өченче абзацта «Федераль теркәү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә» сүзләрен «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә» сүзләренә алмаштырырга.

3. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервын формалаштыру өчен җир кишәрлекләренә инвентаризация ясау турында» 2004 ел, 16 август, 375 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең аерым актлары үз көчен югалткан дип тану һәм аларга үзгәрешләр кертү турында» 2005 ел, 14 декабрь, 603 нче карарының 2 пунктындагы унынчы абзацы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин